ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 18 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«инвалидларны социомәдәни реабилитацияләү һәм абилитацияләү – инвалидларны җәмгыятькә социаль яраклаштыру һәм интеграцияләү максатларында инвалидларны (шул исәптән инвалид балаларны) аларның мәнфәгатьләре һәм сәләтләре нигезендә инвалидларның мәдәни һәм икътисадый ихтыяҗларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган иҗади эшчәнлеккә җәлеп итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы.»;

2) 17 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа уналтынчы абзац өстәргә:

«инвалидларны (шул исәптән инвалид балаларны) социомәдәни реабилитацияләүне һәм абилитацияләүне оештыру өчен шартлар тудыру;»;

б) уналтынчы абзацны унҗиденче абзац дип санарга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 25 апрель
№ 27-ТРЗ